ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА МЕНЗЕЛИНСКА
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКСЫ
МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ МИНЗӘЛӘ ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
от 25.03.2026

КАРАР
№ 56

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы боерыгы проекты буенча ачык тыңлауларны билгеләү турында

«Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы «Минзәлә шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре белән шәхси торак йортлар төзү зонасында «магазиннар» -Татарстан Республикасы, Минзәлә муниципаль районы, Минзәлә шәһәре, Челнинский тракт урамы, 8 нче җир кишәрлеге адресы буенча урнашкан 16:28:180136:280 кадастр номерлы, мәйданы 427 кв.м булган җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында»

Россия Федерациясенең Шәһәр төзелеше кодексына, 06.10.2003 № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законына һәм Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Минзәлә шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына ярашлы, Минзәлә муниципаль районы Минзәлә шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе **карар чыгарды:**

1. «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы «Минзәлә шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре белән шәхси торак йортлар төзү зонасында «магазиннар» -Татарстан Республикасы, Минзәлә муниципаль районы, Минзәлә шәһәре, Челнинский тракт урамы, 8 нче җир кишәрлеге адресы буенча урнашкан 16:28:180136:280 кадастр номерлы, мәйданы 427 кв.м булган җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында»

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы боерыгы проекты буенча ачык тыңлаулар уздыруны билгеләргә.

2. Ачык тыңлауларны оештыручы составын - коллегиаль киңәшмә органын расларга:

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Чухланцев Д.А.;

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының "ПИЗО" МКУ рәисе Шакиров Р.С.;

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге башлыгы урынбасары-баш архитектор Петров В.К.

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге башлыгы Басков Е. А.,

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Советының юридик сектор мөдире Петрова А.В.

3. Ачык тыңлауларны оештыручыга ачык тыңлауларны җирле үзидарә турындагы, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы кануннар нигезендә оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә.

4. Ачык тынлауларны үткәрү чорын билгеләү – 2026 елның 1 апрельдән 2026 елның 10 апреленә кадәр. Ачык тыңлауларны үткәрү вакыты - 2026 елның 13 апреленә кадәр.

5. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырылып чыгарга тиеш.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Р.Р. Шәйсуваров